| СОВЕТ СМАИЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СМӘЕЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** — **КАРАР**

29 ноябрь 2024 ел — № 110

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлеге территориясендә Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертү турында**

2024 елның 8 августындагы «Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 289-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлеге территориясендә Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә :

1.1. 4.6.4 пунктта " 66 статьясындагы 12 өлешендә» сүзләрен «66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга.;

1.2. 4.7.10 пунктта " 66 статьясындагы 12 өлешендә» сүзләрен «66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга.;

1.3. 4.9.5 нче пункт түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
4.9.5. Урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге нигезләмәдәге 4.2.1 пунктының 2 пунктчасында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының (pravo.tatarstan.ru)рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының (baltasi.tatarstan.ru) рәсми сайтында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Смәел авыл җирлеге башлыгы: Р.Г.Йосыпов